КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 18 май г.Казань № б-1083

Татарстан Республикасында ел саен үткәрелә торган «Югары социаль нәтиҗәлелектәге Россия оешмасы» бөтенроссия конкурсының республика этабын үз вакытында әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итү, бу өлкәдәге уңай тәҗрибәне тарату һәм бүләкләү, социаль партнерлыкны үстерү формаларын камилләштерү максатларында:

1. Бу боерыкка теркәлгән 2022 елда Татарстан Республикасында «Югары социаль нәтиҗәлелектәге Россия оешмасы» бөтенроссия конкурсының республика этабын үткәрү чаралары планын (алга таба – Конкурс, План) расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Конкурс үткәрү тәртибе һәм аны оештыруга, йомгаклар ясауга һәм җиңүчеләрне бүләкләүгә бәйле башка мәсьәләләр турында кызыксынучы затларга мәгълүмат бирүне оештырырга.

3. Республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләренә:

Планда каралган чараларның үтәлешен тәэмин итәргә;

эшчәнлекнең җавап бирә торган өлкәсендәге оешмаларны Конкурста катнашуга җәлеп итү һәм аларга анда катнашу өчен кирәкле документлар пакетын әзерләүдә һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына үз вакытында кертүдә ярдәм күрсәтү максатларында әлеге оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү өчен җаваплы затны билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасының Һөнәр берлекләре федерациясенә, Татарстан Республикасы эш бирүчеләре берләшмәләренең координация советына төрле милек рәвешендәге оешмаларны Конкурста катнашуга җәлеп итү буенча чаралар күрүне тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Конкурсны массакүләм мәгълүмат чараларында даими яктыртуны оештырырга.

6. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 18 май, б-1083 нче
боерыгы белән расланды

## 2023 елда Татарстан Республикасында «Югары социаль нәтиҗәлелектәге Россия оешмасы» бөтенроссия конкурсының республика этабын үткәрү буенча чаралар планы

| Т/с | Чаралар | Җаваплы башкаручылар | Үтәү срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы оешмаларга «Югары социаль нәтиҗәлелектәге Россия оешмасы» бөтенроссия конкурсының (алга таба – Конкурс) республика этабын үткәрү шартлары һәм тәртибе турында, заявкалар бирү сроклары һәм Конкурсны оештыруга бәйле башка мәсьәләләр турында мәгълүмат бирү.<br>Массакүләм мәгълүмат чараларында (шул исәптән вакытлы басмаларны, радио, телевидение, интернет-ресурсларны кертеп) Конкурс чараларын яктырту | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы;<br>Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;<br>республика башкарма хакимият органнары;<br>Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары (килешү буенча);<br>Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе (килешү буенча);<br>Татарстан Республикасы эш бирүчеләре берләшмәләренең координация советы (килешү буенча) | Конкурс үткәрү чоры дәвамында |
| 2. | Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы оешмалар өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | министрлыгының рәсми сайтында Конкурсны үткәрү шартлары һәм тәртибе, заявкаларны бирү сроклары һәм аны оештыруга бәйле башка мәсьәләләр турында мәгълүмат урнаштыру | | министрлыгының конкурс үткәрү турындагы беркетмәсен алган көннән биш календарь көн эчендә |
| 3. | Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы оешмаларны Конкурста катнашуга җәлеп итү, аларга Конкурста катнашу өчен кирәкле документлар пакетын әзерләүдә һәм үз вакытында җибәрүдә ярдәм күрсәтү буенча эшләр башкару | Республика башкарма хакимият органнары;<br>Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары (килешү буенча);<br>Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе (килешү буенча);<br>Татарстан Республикасы эш бирүчеләре берләшмәләренең координация советы (килешү буенча) | 2023 елның 20 маена кадәр |
| 4. | Конкурста оешмалар катнашуга заявкаларны Конкурс үткәрү буенча методик тәкъдимнамәләрдә каралган тәртиптә кабул итү | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;<br>Конкурсның республика этабында катнашучыларның материалларын карап тикшерү өчен экспертлар эшче төркеме | 2023 елның 20 маена кадәр |
| 5. | Оешмаларның заявкаларын Конкурс үткәрү буенча методик тәкъдимнамәләр нигезендә алдан карап тикшерү.<br>Конкурста катнашырга рөхсәт ителгән оешмаларның заявкаларында бирелгән мәгълүматларның дөреслеген тикшерү. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;<br>Конкурсның республика этабында катнашучыларның материалларын карап тикшерү өчен экспертлар эшче төркеме;<br>Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспек- | 2023 елның 1 июненә кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | Оешмаларның заявкаларын бәяләү, Конкурста катнашучылар арасында призлы урыннарны бүлү турында тәкъдимнәр әзерләү | циясе (килешү буенча);<br>Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча);<br>Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре идарәсе (килешү буенча);<br>«Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге (килешү буенча);<br>«Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесе (килешү буенча) | |
| 6. | Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе утырышында Конкурс үткәрү йомгакларын карап тикшерү өчен материаллар әзерләү | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;<br>Конкурсның республика этабында катнашучыларның материалларын карап тикшерү өчен экспертлар эшче төркеме | 2023 елның 5 июненә кадәр |
| 7. | Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе утырышында Конкурста җиңүчеләр һәм җиңүчеләрне федераль дәрәҗәдәге Конкурста катнашуга номинацияләү турындагы тәкъдимнәр белән Конкурс үткәрү йомгаклары турындагы материалларны карап тикшерү | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;<br>Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе | 2023 елның 15 июненә кадәр |
| 8. | Конкурста җиңүчеләрнең электрон материалларын Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының мәгълүмат | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2023 елның 1 июленә кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | порталында (http://14-ot.rosmintrud.ru) урнаштыру | | |
| 9. | Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе утырышында Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын әзерләү һәм үткәрү, аны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итү | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;<br>Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе<br>Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | 2023 елның 1 декабренә кадәр |